**Карар № 87**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Яңа Шашы авыл җирлеге Советы**

Яңа Шашы авылы 30 январь 2024 ел

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге 106 нчы номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге 106 номерлы «Җир салымы турында» карарына (20.01.2020 №120, 30.10.2020 №7 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2.2 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә;

«2.2. 0,12 процент эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеш өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләре, торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлегенең бер өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата кулланыла».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (www.atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар имза салынган көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 январе белән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы: Сабирҗанов М.С.